КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 25 февраль г.Казань № 114

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль хезмәтләр күрсәтү өчен түләү күләмен һәм аны алу тәртибен раслау турында» 2014 ел, 29 ноябрь, 927 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 13 март, 151 нче, 2015 ел, 4 ноябрь, 835 нче, 2020 ел, 29 июнь, 540 нчы, 2021 ел, 18 июнь, 479 нчы, 2023 ел, 28 август, 1030 нчы, 2023 ел, 8 декабрь, 1578 нче, 2024 ел, 25 май, 365 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), 1 пунктның икенче абзацында «2014 елның 18 октябрендәге 1075 номерлы» сүзләрен «2024 елның 23 декабрендәге 1873 номерлы» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип танылган юридик хокуклы өлкән яшьтәге гражданнар өчен тәрбиягә алган гаиләләрне булдыру тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәне раслау хакында» 2016 ел, 31 август, 604 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 20 март, 157 нче, 2017 ел, 8 декабрь, 961 нче, 2018 ел, 5 апрель, 208 нче, 2018 ел, 29 декабрь, 1284 нче, 2020 ел, 19 август, 708 нче, 2022 ел, 6 апрель, 321 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип танылган юридик хокуклы өлкән яшьтәге гражданнар өчен тәрбиягә алган гаиләләрне булдыру тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәгә, «2014 елның 18 октябрендәге 1075 номерлы» сүзләрен «2024 елның 23 декабрендәге 1873 номерлы» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин